

ҖИР ЙӨЗЕНДӘ ТЫНЫЧЛЫК ,ДУСЛЫК, МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК, ГАДЕЛЛЕК БУЛСЫН!

№3 Январь Февраль Март 2021 нче ел

# МӘКТӘП СУЛЫШЫ

## Бу санда

## 2021 ел- Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы

Татарстанда 2021 ел Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Аның максаты – Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның туган телләрен, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү, шулай ук республиканың күпмилләтле халкының бердәмлеген ныгыту.

Дөньяда бик күп телләр бар, ләкин һәр кешегә иң матур һәм иң яраткан тел – ул туган тел. Күп кешеләр башка телләрне дә яхшы беләләр, әмма туган тел барыбер аларның һәрберсе өчен иң кадерле. Туган тел аша без дөнья белән танышабыз. Ул белемнең һәм акылның саклаучысы. Туган үскән илнең якынлыгын, Ватанның газизлеген тоярга да безгә туган тел ярдәм итә. Туган тел хезмәт белән бергә кешене үстерә , аңа Ватанның тарихын белергә, милли сәнгатен аңларга, яратырга ярдәм итә.

2 нче санлы Урыссу урта мәктәбендә «2021 ел- туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы» исеме астында чаралар үткәрү башланып китте.

*2021 ел-Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы*

*Туган телләр атналыгы*



*Мәдәният хезмәткәрләре белән очрашу*



# Туган телләр атналыгы

15-25 февральдә мәктәбебездә “Туган телләр”ункөнлеге үтте. Безнең мәктәптә бу көн олы бәйрәм төсен алды. Бәйрәмгә әзерлек бер ай алдан башланды. Һәр класс туган телгә багышлап стена газеталары чыгарды. Укучылар телгә багышланган иншалар, шигырьләр яздылар, викторина сораулары, ребуслар, башваткычлар төзеделәр, тел галимнәре, тел турында кызыклы материаллар тупладылар. Туган телгә карата ихтирам, сөю хисе тәрбияләү, тел байлыгын арттыру максатыннан “Туган тел” ункөнлеге кысаларында мәктәптә бик күп күңелле чаралар уздырылды. Укучыларыбыз бик теләп катнаштылар.















Тулырак мәълүматны https://vk.com/club144505055 сылтамасы аша кереп карый аласыз.

# *Тәмле булсын*

***Бүген бәйрәм табынына кабак бәлеше әзерлибез. Бәлеш** – татар халкының табын күрке булган милли ризыкларының берсе.*

**Кабак бәлеше:**
**Камыр ясау өчен:** 2 аш кашыгы йомшартылган акмай, 2 аш кашыгы үсемлек мае, 1 йомырка, тоз, 300-350 г он.

**Эчлеге өчен:** 1 кг кабак, 1 ст дөге, 50 г акмай, 100 г йөзем, шулай ук өрек, каражимеш салырга да мөмкин.

Камырны басып, ярты сәгать каплап торабыз. Алдан бүрттерелгән дөге янына туралган кабак, йөзем, тәменчә тоз, 1-2 аш кашыгы шикәр кушып, эчлек ясыйбыз. Камырның бер өлешен җәеп, майлы табага салгач, эчлекне тигезләп җәябез. Өстенә акмай телемнәре салып чыгабыз. Камырның икенче өлешеннән бәлешкә капкач җәябез һәм аны ябып, читләрен матурлап бөрәбез. Кабак бәлешен 1-1,5 сәгать пешә.













***Бәйрәм сыебыз әзер! Ашларыгыз тәмле булсын!***



# Мәдәният хезмәткәрләре белән очрашу

*Бүген бездә кунакта*

Мәдәният хезмәткәре – һөнәр генә түгел, ул сәнгать аша кешеләрнең күңелен, рухын дәвалаучы, дөньяга матурлык өстәүче. Чөнки мәдәният өлкәсе – иҗат казаны, җыр-моң, шигърият сөючеләрне яшәшәсенә туплаучы көч. Биредә чын иҗат кешесе булмасаң, кешеләрне ярата, тәэсир итәрлек сүзләр таба белмәсәң, әлеге һөнәрнең асылына төшенү, аңа чын мәгънәсендә бирелеп эшләп булмый.

Туган телләр көненә, Ютазы районының 30 еллыгына багышлап, мәктәбебездә якташ мәдәният хезмәткәрләре белән очрашу булды. Анда Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе Абдурахманова Минзилә Маузир кызы һәм Ютазы рйонының яшь җырчысы Миңнуллин Малик Марат улы катнашты. Сәнгать осталары үзләренең иҗат юллары турында сөйләделәр һәм укучыларны кызыксындырган сорауларга җавап бирделәр. Очрашу җырлар, биюләр белән үрелеп барды.



















# ***Балалар иҗаты***

***Бүгенге иҗатыбыз М.Җәлил шигырьләренә багышлана.***



Махиянов Марсель,

5 нче Б сыйныфы укучысы



Камалова Зарина,

6 нчы А сыйныфы укучысы




Шарипов Данияр,

3 нче А сыйныфы укучысы



Ибрагимова Алина,

4 нче Б сыйныфы укучысы




Желенков Арсений,

4 нче А сыйныфы укучысы



# *Калфак*

Калфак – барлык татарларда да киң таралган, шулай ук керәшен татарларында да сакланып калган борынгы хатын-кызларның баш киеме. Калфак классик татар милли киемнәренең аерылгысыз өлешенә әверелде. Калфак сәйлән белән бизәлә.



XVIII-XX гасырлар эчендә калфакның үлчәме, милли бизәкләре бик нык үзгәргән. Элегерәк йомшак материалдан эшләнгән бөтен башны каплый торган калфаклар эшләгәннәр.

XVIII гасырда аппликация технологиясе кулланыла, эреле-ваклы төрле төстәге тукыма кисәкләреннән өчпочмак итеп катлап салынган колакчыннар тегелә башлый. Калфакны бәрхет материалдан тегәләр, кулбашка төшеп торган чуклы тасма белән бизи башлыйлар.



Соңрак авыр тасмалар, чуклар югала, калфак кечерәк һәм уңайлырак итеп тегелә. Каты кырлаулы калфакларны шәл һәм яулык астында киеп йөриләр. XX гасыр башында татар хатын-кызлары арасында, нигездә, зыялылар вәкилләре һәм шәһәр халкы арасында Аурупа кием-салым формасы киң тарала, әмма калфак хатын-кызның милләтен билгеләгән традицион баш киеме булып кала. Совет чорында калфак көндәлек баш киеме булудан туктый һәм бары тик бәйрәмнәрдә яки милли кием сыйфатында гына сәхнә костюмына әверелде. Ә хәзер хатын-кызларыбыз кечкенә калфакларны төрле чараларда катнашканда, хәтта көндәлек тормышта да яратып кия башладылар.

**Гәҗитне басмага әзерләделәр:**

6 нчы сыйныф укучылары

Җитәкчеләре: Хөсәенова Л.Т.

***Сездән язмалар көтеп калабыз!***